**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

04.02.2015 ел № 57/1

# КАРАР

Әҗмәкәй авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Ро9сий Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Азьмушка авыл җирлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә җирле референдумны Әҗмәкәй авыл җирлегендә үткәрү турында инициативаны җирле референдумның сорауларын түбәндәгечә формалаштырып чыгарырга:

«1) 2015 елда Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 100 (йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүләрне Әҗмәкәй к авыл җирлеге территориясендә сорауларны хәл итүгә кертергә ризамы?

а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) эшчәнлеген булдыруны һәм тәэмин итүне, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын муниципаль тикшереп торуны гамәлгә ашыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

б) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту;

в) алар урнашкан биналарны (торак йортларны да кертеп) һәм җир кишәрлекләрен карап тоту таләпләрен билгели торган җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, тиешле биналарның һәм корылмаларның тышкы күренешенә, аларны төзекләндерү һәм үтәү эшләре исемлегенә, тиешле биналарның һәм корылмаларның тышкы кыяфәтенә, аларның фасадларын һәм коймаларын тыштан карап тоту кагыйдәләрен раслау; якындагы территорияләрне төзекләндерүдә биналар (алардагы биналар) милекчеләренең катнашу тәртибен билгеләү; җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарны һәм йортларның исемнәре белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны кертеп), шулай ук җирлек чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләрендә аеруча саклана торган шәһәр урманнарында, урманнардан файдалану, аларны саклау, торгызу, торгызу тәртибен билгеләү;

г) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне кертеп;

д) көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм алып китүне оештыру.

2) I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз картлар һәм көндезге формада белем алучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен түләү күләмен киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 50 (илле) сум күләмендә билгеләргә килешәсезме?

Әлеге карарны Тукай территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында урнаштырып халыкка җиткерергә.

Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.Г. Фазылҗанов